# ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Үтәгән торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**03.12. 2021** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Үтәгән торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2021 елның 03 декабрендә 10:30 сәг уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Үгәгән торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1) Үтәгән авылында урамнарны яктырту өчен светодиод лампалар сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү;

2) Үтәгән авылында халыкны су белән тәэмин итүне карап тоту (ремонт, хезмәт күрсәтү, түләү, су белән тәэмин итү өчен тирәнлек насослары һәм төзелеш материаллары сатып алу);

3) Үтәгән авылында юлларны кардан чистарту - юлларга хезмәт күрсәтү;

4) Үтәгән авылында корыган агачларны кисү;

5) Үтәгән авылында су алу башнялары һәм скважиналары өчен җирләрне межалау;

6) Үтәгән авылы мәдәният йортының техник документациясен эшләү;

7) хуҗасыз йортларны карап тоту, тышкы фасадларны яңарту, койма белән әйләндереп алу;

8) Үтәгән авылында Үзәк урам буенча күперне ремонтлау (материаллар сатып алу һәм килешү буенча эш өчен түләү);

9) янгын сүндерү автомобиле өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 153 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 80 кеше, бу 52,2 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 80 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының ««Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Үтәгән торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенынын нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. 2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Үтәгән торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1) Үтәгән авылында урамнарны яктырту өчен светодиод лампалар сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү;

2) Үтәгән авылында халыкны су белән тәэмин итүне карап тоту (ремонт, хезмәт күрсәтү, түләү, су белән тәэмин итү өчен тирәнлек насослары һәм төзелеш материаллары сатып алу);

3) Үтәгән авылында юлларны кардан чистарту - юлларга хезмәт күрсәтү;

4) Үтәгән авылында корыган агачларны кисү;

5) Үтәгән авылында су алу башнялары һәм скважиналары өчен җирләрне межалау;

6) Үтәгән авылы мәдәният йортының техник документациясен эшләү;

7) хуҗасыз йортларны карап тоту, тышкы фасадларны яңарту, коймала белән әйләндереп алу;

8) Үтәгән авылында Үзәк урам буенча күперне ремонтлау (материаллар сатып алу һәм килешү буенча эш өчен түләү);

9) янгын сүндерү автомобиле өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу.

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Авыл җирлеге башлыгы Д.М.Әхмәтов

Совет Старосляковского сельского поселения
Иске Эсләк авыл җирлеге Советы
АГРЫЗСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИНН 1601002580